**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге советы**
**Карары**

**№ 79** **“19” сентябрь 2018 ел**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авылы җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе, 2018 елның 17нче сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 10 номерлы карары, 2018 елның 19нчы сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 78 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авылы җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авылы җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

а) вак таш түшәлгән юлны ремонтлау:

- Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, Аркылы урам - 1, Аркылы урам - 2 буенча;
- Малаевка авылы, Двойная урамы буенча;
- Олы Карамалы авылы, Татарстан урамы, И. Гази урамы, Мәктәп урамы буенча.

б) юлларны кышын карап тоту:

- Олы Карамалы авылы,
- Бәрлегуҗа авылы,
- Архангельск Келәре авылы.

*** Күмү урыннарын карап тоту:**

- Архангельск Келәре авылы зиратын ремонтлау.

*** Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**

- Олы Карамалы, Бәрлегуҗа авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (шул исәптән чүп үләннәрен чабу).

*** Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру**

- Олы Карамалы, Бәрлегуҗа авылларыннан чүпне чыгару.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк урам, 4 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16 йорт,

шулай ук “Волжские зори” (“Идел таннары”) газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**

**Олы Карамалы авыл җирлеге**
**Башлыгы, Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Олы Карамалы авыл**
**җирлеге Советы рәисе** **Э. И. Бәйдамшин**